**Маснурова Лилия Әмир кызы**



Маснурова Лилия Әмир кызы 1955 елның 21 апрелендә Татарстан Республикасы Мөслим районы Мөслим авылында туа. 1972 елда Мөслим урта мәктәбен тәмамлый. 1977 елда шәфкать туташы белгечлеге буенча Минзәлә медицина училищесын тәмамлый.

Яшь белгеч Мөслимгә, туган ягына әйләнеп кайта. 1977-1979 елларда үзәк хастаханәдә хирургия бүлегендә шәфкать туташы булып эшли. 1981 елда ветеринария табибы белгечлеге буенча Казан дәүләт ветеринария институтын тәмамлый, шул ул ук елны авыл хуҗалыгы идарәсендә дә эшли.

Лилия Әмировна 1982 елда 1 нче Мөслим урта мәктәбенә авыл хуҗалыгы фәннәрен укытырга чакырыла. Ул, лаеклы ялга чыкканчы, Мөслим лицеенда технология укытучысы булып эшли. Укучылары һәм хезмәтәшләре аны бик төгәл, үз эшен яратып башкаручы, тыйнак, хезмәт сөючән һәм пөхтә итеп тасвирлыйлар.

Лилия Әмировнаның укучылары күп кенә фән олимпиадаларында, муниципаль һәм республика дәрәҗәсендәге конкурсларда катнаштылар, призлы урыннар яуладылар. Моннан тыш, ул лицейның бакча участогы өчен дә җаваплы иде. Анда нинди генә яшелчә үсмәде: кишер, чөгендер, суган, укроп, петрушка, помидор, кыяр һәм хәтта кәбестә! Җәй көннәрендә укучылар мәктәп яны участогында карлыган җыеп кайнатма пешерделәр, карлыган яфракларын киптереп, витаминлы чәй әзерләделәр. Күп тапкырлар лицейның мәктәп яны участогы «иң төзек, чиста һәм матур» дип билгеләп үтелде. Җәй әйләнәсе лицей территориясе төрле чәчәкләргә күмелеп утырды. Монда да Лилия Әмиронаның да өлеше зур!

2006 нчы елда ул Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы грамотасы белән бүләкләнде.

2008 нче елда "Педагогик инновацияләр" Бөтенроссия ачык конкурсының 2нче дәрәҗә Дипломына ия булды.

2008 нче елда «Иң яхшы мәктәп яны укыту-тәҗрибә участогы» Республика конкурсында җиңү яулап, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы грамотасы белән бүләкләнде.

Әмма бүгенге көндә Лилия Әмировна үз гаиләсен, балаларын төп байлыгы һәм казанышы дип саный. Тормыш иптәше Радик белән өч бала - ике ул һәм бер кыз тәрбияләп үстерәләр. Ул яраткан хатын, әни, дәү әни булуы белән бәхетле һәм бүгенге халәте белән канәгать.